КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 6 июль № 487

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 1 ноябрь, 518 нче; 2005 ел, 6 декабрь, 574 нче; 2006 ел, 16 март, 103 нче; 2006 ел, 21 апрель, 201 нче; 2008 ел, 18 апрель, 239 нчы; 2008 ел, 22 декабрь, 911 нче; 2010 ел, 17 июнь, 482 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1034 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 30 сентябрь, 815 нче; 2012 ел, 10 август, 696 нчы; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2013 ел, 18 март, 173 нче; 2013 ел, 25 июль, 525 нче; 2014 ел, 6 март, 141 нче; 2014 ел, 13 август, 586 нчы, 2015 ел, 21 май, 363 нче, 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы кысаларында, мәгълүматны җыюны, саклауны, эшкәртүне һәм анализлауны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау

системасы эшен фәнни-методик тәэмин итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруны мониторинглау һәм анализлауны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән хезмәттәшлек вазыйфаларын башкара;

үз компетенциясе чикләрендә экстремистик эшчәнлеккә һәм террорчылыкка каршы торуда катнаша, Министрлыкка беркетелгән объектларның террорчылыкка каршы саклануын тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\487.docx